**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2015 елның «14» декабреннән № 349

**«Яңа Чишмә муниципаль районы халкының бәйрәм фейерверкларын кулланганда куркынычсызлыгы турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 2015 елның 3 декабрендәге 913 номерлы карары нигезендә, яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәрен уздырганда пиротехника әйберләрен куллануга бәйле халыкның иминлеген тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. Яңа Чишмә авылында Яңа Чишмә авылыннан 1000 м ераклыкта Екатерина Бистәсе авылына таба бәйрәм фейерверклары үткәрү урынын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында фейерверклар җибәрү урынын урнаштыру схемасын расларга. (1 нче кушымта).

3. Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына, «Төнлә гражданнарның тынычлыгын саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен үтәп, барлык торак пунктларда, бәйрәм фейерверкларын куллану өчен мәйданчыкларны (стадионнар, парклар) беркетергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **В.Н.Семеняк**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «14» декабрендәге
349 номерлы карарына
1 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕЙЕРВЕРКЛАР ҖИБӘРҮ УРЫНЫН УРНАШТЫРУ СХЕМАСЫ

